**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 февраль № 104

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы; 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче; 2011 ел, 28 апрель, 347 нче; 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы; 2011 ел, 25 июль, 576 нчы; 2011 ел, 19 август, 688 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нче; 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче; 2012 ел, 25 апрель, 323 нче; 2012 ел, 1 июнь, 464 нче; 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче; 2013 ел, 29 апрель, 298 нче; 2013 ел, 29 июнь, 457 нче; 2013 ел, 26 август, 600 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2 бүлектә:

2.4 нче пункттагы «Мәгариф хезмәткәренең (оклады бу Нигезләмәнең 2.5 нче пункты белән билгеләнгән педагог хезмәткәрдән тыш) база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:» сүзләрен «Мәгариф хезмәткәренең (оклады бу Нигезләмәнең 2.5 нче пункты белән билгеләнгән педагог хезмәткәрдән һәм оклады бу Нигезләмәнең 2.6 нчы пункты белән билгеләнгән яшьләр сәясәте

учреждениеләренең мәгариф тармагы хезмәткәреннән тыш) база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:» сүзләренә алыштырырга;

2.6 – 2.9 нчы пунктларны тиешенчә 2.7 – 2.10 нчы пунктлар дип санарга;

бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.6 нчы пункт өстәргә:

«2.6. Яшьләр сәясәте учреждениеләренең мәгариф тармагы хезмәткәренең база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$«O_b = T_1 \times K_{m_i} + K_{mjmp},$$

монда: $K_{mjmp}$ - тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты.

Тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты күләме яшьләр сәясәте учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләре база окладын хисап чыгару өчен кулланыла һәм 1,7 тәшкил итә.»;

11 бүлектәге 11.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.4. Белем бирү учреждениесе һәм яшьләр сәясәте учреждениесе финанслау нормативы, кулланучылар саны һәм төзәтү коэффициенты нигезендә хисаплап чыгарылган акчаның гомуми күләмендә хезмәткәрләргә окладлар (эш хакы ставкаларын, вазыйфаи окладлар) түләүгә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фондыннан эшнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүгә акча күләмен гомуми белем бирү оешмаларында, мәктәпара уку-укыту-комбинатларында – кимендә 40 процент, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларда, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында – кимендә 26 процент, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмаларында – кимендә 20 процент, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында – кимендә 15 процент һәм башка белем бирү, физик культура һәм спорт оешмаларында һәм яшьләр сәясәте учреждениеләрендә кимендә 10 процент күләмендә мөстәкыйль рәвештә билгели.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2 бүлектә:

2.4 нче пункттагы «Мәдәният хезмәткәренең база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:» сүзләрен «Мәдәният хезмәткәренең (оклады бу Нигезләмәнең 2.5 нче пункт белән билгеләнгән яшьләр сәясәте учреждениеләренең мәдәният тармагы хезмәткәреннән тыш) база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:» сүзләренә алыштырырга;

2.5 – 2.8 нче пунктларны тиешенчә 2.6 – 2.9 нчы пунктлар дип санарга;

бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.5 нче пункт өстәргә:

«2.5. Яшьләр сәясәте учреждениеләренең мәдәният тармагы хезмәткәре база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$«O_b = T_1 \times K_{m_i} + K_{mjmp},$$

монда: $K_{mjmp}$ - тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты.

Тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты күләме яшьләр сәясәте учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре база окладын хисап чыгару өчен кулланыла һәм 1,7 тәшкил итә.»;

5 бүлектәге 5.22 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.22. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең башкарыла торган эшләре сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләргә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фонды күләме хезмәткәрләргә төп эш урыны буенча окладлар (эш хакы ставкаларын, вазыйфаи окладлар) түләүгә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фондыннан гомуми белем бирү оешмаларында – кимендә 40 процент, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларда, мәктәпара уку-укыту комбинатларында, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында – кимендә 26 процент, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмаларында – кимендә 20 процент, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында – кимендә 15 процент һәм башка белем бирү, физик культура һәм спорт оешмаларында һәм яшьләр сәясәте учреждениеләрендә кимендә 10 процент тәшкил итә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләренең  хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2 бүлектә:

2.4 нче пункттагы «Физик культура һәм спорт хезмәткәренең база оклады (эш хакының база ставкасы) түбәндәге формула буенча исәпләнә:» сүзләрен «Физик культура һәм спорт хезмәткәренең (окладны бу Нигезләмәнең 2.5 нче пункты белән билгеләнгән яшьләр сәясәте учреждениеләренең физик культура һәм спорт тармагы хезмәткәреннән тыш) база окладны (эш хакының база ставкасы) түбәндәге формула буенча исәпләнә:» сүзләренә алыштырырга;

2.5 – 2.8 нче пунктларны тиешенчә 2.6 – 2.9 нчы пунктлар дип санарга;

бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.5 нче пункт өстәргә:

«2.5. Яшьләр сәясәте учреждениеләренең физик культура һәм спорт тармагы хезмәткәре база окладны түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$«O_b = T_1 \times K_{m_i} + K_{mjmp},$$

монда: $K_{mjmp}$ - тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты.

Тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты күләме яшьләр сәясәте учреждениеләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре база окладын хисап чыгару өчен кулланыла һәм 1,7 тәшкил итә.»;

10 бүлектәге 10.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.5. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең башкарыла торган эшләре сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләргә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фонды күләме хезмәткәрләргә төп эш урыны буенча окладлар (эш хакы ставкаларын, вазыйфаи окладлар) түләүгә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фондыннан гомуми белем бирү учреждениеләрендә – кимендә 40 процент, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларда, мәктәпара уку-укыту комбинатларында, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында – кимендә 26 процент, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмаларында – кимендә 20 процент, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында – кимендә 15 процент һәм белем бирү, физик культура һәм спорт оешмаларында һәм башка яшьләр сәясәте учреждениеләрендә кимендә 10 процент тәшкил итә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2 бүлектә:

2.4 нче пункттагы «Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:» сүзләрен «Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең (оклады бу Нигезләмәнең 2.5 нче пункты белән билгеләнгән яшьләр сәясәте учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләреннән тыш) база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:» сүзләренә алыштырырга;

2.5 – 2.8 нче пунктларны тиешенчә 2.6 – 2.9 нчы пунктлар дип санарга;

бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.5 нче пункт өстәргә:

«2.5. Яшьләр сәясәте учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$«O_b = T_1 \times K_{m_i} + K_{mjmp},$$

монда: $K_{mjmp}$ - тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты.

Тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты күләме яшьләр сәясәте учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре база окладын хисап чыгару өчен кулланыла һәм 1,7 тәшкил итә.»;

5 бүлектәге 5.23 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.23. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең башкарыла торган эшләре сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләргә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фонды күләме хезмәткәрләргә төп эш урыны буенча окладлар (эш хакы ставкаларын, вазыйфаи окладлар) түләүгә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фондыннан гомуми белем бирү оешмаларында – кимендә 40 процент, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларда, мәктәпара уку-укыту комбинатларында, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында – кимендә 26 процент, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү

оешмаларында – кимендә 20 процент, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында – кимендә 15 процент һәм башка белем бирү, физик культура һәм спорт оешмаларында һәм яшьләр сәясәте учреждениеләрендә кимендә 10 процент тәшкил итә.».

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\104.doc